| | | |
|---|---|---|
| **КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 22 июль № 540

г. Казань

Кайбер белем бирү оешмаларын үзгәртеп оештыру һәм «Кама дәүләт автомеханика техникумы» һөнәри белем бирүче дәүләт автоном учреждение-сенең исемен үзгәртү турында

Татарстан Республикасының һөнәри белем бирү оешмалары челтәрен оптимальләштерү, квалификацияле эшчеләрне һәм урта звено белгечләрен әзерләү сыйфатын күтәрү, кадрларны әзерләү күләмнәрен арттыру һәм хезмәт ресурсларыннан нәтиҗәлерәк файдалану максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Л.Б.Васильев исемендәге Кама политехника көллияте» һөнәри белем бирүче дәүләт автоном учреждениесен (алга таба – Л.Б.Васильев исемендәге Кама политехника көллияте) «Кама дәүләт автомеханика техникумы» һөнәри белем бирүче дәүләт автоном учреждениесенә (алга таба – Кама дәүләт автомеханика техникумы) кушу юлы белән, Кама дәүләт автомеханика техникумы эшчәнлегенең төп максатларын саклап, Кама дәүләт автомеханика техникумын һәм Л.Б.Васильев исемендәге Кама политехника көллиятен үзгәртеп оештыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Кама дәүләт автомеханика техникумының исемен «Л.Б.Васильев исемендәге Кама дәүләт автомеханика техникумы» һөнәри белем бирүче дәүләт автоном учреждениесенә (алга таба – Л.Б.Васильев исемендәге Кама дәүләт автомеханика техникумы) үзгәртергә.

3. Л.Б.Васильев исемендәге Кама дәүләт автомеханика техникумының дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләре башкаруга) дәүләт йөкләмәсен үтәвен финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм аның үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2010 ел, 29 апрель, 308 нче карары нигезендә, Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында тиешле финанс елына һәм план чорына әлеге максатларга күздә тотылган акча чикләрендә гамәлгә ашырыла, дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

Л.Б.Васильев исемендәге Кама дәүләт автомеханика техникумын гамәлгә куючы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен башкарырга;

әлеге карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән белем бирү оешмаларын үзгәртеп оештыруга һәм Кама дәүләт автомеханика техникумының исемен үзгәртүгә бәйле, законнар белән күздә тотылган чараларны үткәрүне тәэмин итәргә;

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 ел, 29 декабрь, ФЗ-273 нче Федераль закон һәм «Мәгариф турында» 2013 ел, 22 июль, ТРЗ-68 нче Татарстан Республикасы Законы таләпләрен үтәп, Л.Б.Васильев исемендәге Кама политехника көллиятендә укучыларны ата-аналары (законлы вәкилләре) ризалыгы белән, укыту шартларын һәм программаларын саклап, Л.Б.Васильев исемендәге Кама дәүләт автомеханика техникумына күчерүне тәэмин итәргә;

үзгәртеп оештыру чаралары нәтиҗәсендә эштән чыгарыла торган хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне законнар нигезендә тәэмин итәргә;

бер ай эчендә:

Л.Б.Васильев исемендәге Кама дәүләт автомеханика техникумы уставын эшләргә һәм расларга;

Кама дәүләт автомеханика техникумы өчен дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләре башкаруга) дәүләт йөкләмәсенә тиешле үзгәрешләрне кертергә.

5. Л.Б.Васильев исемендәге Кама дәүләт автомеханика техникумы уставы дәүләт теркәвенә алынганнан соң, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына:

30 көн эчендә элек оператив идарә хокукында Л.Б.Васильев исемендәге Кама политехника көллиятенә беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен оператив идарә хокукында Л.Б.Васильев исемендәге Кама дәүләт автомеханика техникумына беркетергә;

60 көн эчендә Л.Б.Васильев исемендәге Кама дәүләт автомеханика техникумына беркетелә торган күчемсез мөлкәт объектлары урнашкан җир кишәрлеген даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында бирүне тәэмин итәргә.

6. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе белән берлектә, Л.Б.Васильев исемендәге Кама дәүләт автомеханика техникумы уставын раслаганнан соң бер ай эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга урта звено белгечләрен әзерләү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм Татарстан Республикасының дәүләт һөнәр белеме бирү оешмалары мөлкәтен карап тотуга нормативлар чыгымнарны раслау турында» 2014 ел, 29 октябрь, 807 нче карарына әлеге карарның 1, 2 нче пунктларына туры китерү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында карар проектын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

7. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\540.docx